СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

12 сентябрь, 1998 ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 104 (8261) | Бәясе билгеләнгәнчә

## УРАКНЫҢ ИКЕНЧЕСЕ КИЛЕП ҖИТТЕ

# БЕР БАСУДА ИКЕ ОСТА

**"Рассвет" КХАсы чөгендерчеләре быел шикәр заводына чималны иң беренче булып китерделәр.**

Тип - тигез басуны урап алган агачларга көзге чуарлык иңеп килә. Көзге кояш бүген аерата юмарт елмая, аның нуры ялтырап торган француз комбайнының зур тәрәзәләрендә уйный, гөрләп үсеп утырган кара - кучкыл чөгендер яфракларын иркәли, яңа чыгарылган татлы тамыр өемнәре янына тезелешкән хатын - кызлар күңеленә дә аның җылысы бик хуш килгәнгә ошый.

Чөгендер басуында эш гөрли. Француз комбайны комбайнчысы Касыйм Сатдаров техникасын азга гына туктаткан да, француз егете Жан Марк белән сөйләшә - сөйләшә май сала. Нурлат игенчеләрен өченче ел инде чит ил техникасы белән эшләргә өйрәтүче французның русчасы шомарган, Касыйм белән, бер кухняда эшләүче апайлар төсле, кыска - кыска җөмләләрдән аңлашалар.

- Районда 9 француз комбайны эшли. Иң яхшы оештыру эшләре дә биредә, иң әйбәт комбайнчы да монда. Әгәр комбайнчы техниканы әйбәтләп карамаса, көйләп эшләтмәсә, аны 2 елдан соң гамәлдән чыгарырга туры килер иде,- ди Жан Марк комбайнчы турында сөйләшә башлагач. Француз егете 2 ел эчендә шулай һәркемне эше - гамәленнән чыгып бәяләргә өлгергән инде: әнә, "Киекле"дән Азат Әхмәтвәлиев, "Игенче"дән Нәгыйм Зәйнуллин шулай ук бер дигән комбайнчылар. Гомумән, Жан Марк әйтүенчә, бездә эшли беләләр, саный гына белмиләр. Ә исәп - хисап булмый торып, тәртип, отыш килмәячәк шул. Француз комбайны, аның әйтүенчә, дистәләгән илләрдә уңышлы эшләп килә, безнең җирлеккә дә ярамаслык түгел. Җир бик каты булганда гына үзебезнең КС - 6ларга егылырга туры килә. Тагын бер ягы бар: өч процессны берүзе башкара торган комбайн чистарткан чөгендерне кабул итү пунктына өстәмә чистартып озатырга туры килә.

- Безнең заводлар нәкъ менә шулай төбендә бераз яшеле калуын шарт итеп куялар, чөнки чөгендернең иң зур шикәрлелеге нәкъ шунда була. Сездә завод моңа әзер түгел. Ә Зәйдә шулай, чистармыйча кабул итәләр,- ди Жан Марк. Икътисадый якны исәпләгәндә, безнең оттыруыбыз күз алдында. Әмма технологик мөмкинлекләрне бер көн эчендә киңәйтеп булмый шул!

Француз татар комбайнчысыннан канәгать. Касыйм исә француз комбайныннан канәгатьлеген сөйли.

- Беренче елны гына уңайсызрак булды. Җир бик каты иде,- ди. - Хәзер үзем карыйм, үзем ремонтлыйм, саклауга куям - һәммәсенә өйрәндем инде.

Бер кулда гына тоткач, комбайны да ялт итеп тора, шөкер, ватылганы да юк. Чөгендер итү остасының хәзер КСка һич утырасы килми. Юк, үзебезнең техниканы юкка чыгару, себереп түгүдән түгел, әнә Жан Марк та аны техника буларак примитив дип бәяләргә җыенмый. Безнең техника идарә итүче өчен уңайлы, камил түгел. Француз комбайнының төймәле идарә итү системасыннан соң аңа яңабаштан ияләшү күңелле түгел шул. Юкса, 18 ел чөгендер үстергән Касыйм элегрәк үзебезнең техника белән дә сынатмый иде. Әмма чөгендер игү бик мәшәкатьле, механизатордан нык игътибарлы эшләүне сорый шул.

- Күзләрем арый,- ди Касыйм. Чөгендерне ул үзе чәчкән, үзе иккән кеше. Хәзер дә француз чәчкече артында үзе эшли. Быел хуҗалыктагы француз технологиясе буенча эшкәртелә торган 200 гектарлы мәйданны үзе чәчте, әле Якты Күлгә, гадәти технология буенча игелә торган басуга да барып булышырга өлгерде. Гел эзне карап, тизлекне саклап бару күзгә төшкәндер шул.

Басуда озын - озаклап сөйләшеп торырга вакыт юк, Касыйм комбайнына ашыкты. Әнә яфрак ургыч һәм доочистительдә эшләүче Рушан Хөсәенов белән Рәис Гобәйдуллин да кузгалып киләләр. Көн әйбәт булганда, тизрәк эшләп калырга кирәк.

Татлы тамыр шулай зур хезмәт белән үстерелә, җыела шул.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**



**Рәсемдә: Жан Марк һәм комбайнчы Касыйм Сатдаров.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## *"Уңыш -98"*
## матбугат үзәге хәбәр итә

***Сабан культураларыннан азмы - күпме бодайны гына җыеп аласы калып бара, анысы да нигездә "Чирмешән", "Алга" һәм "Татарстан"да һәм нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында. Шуңа да бүген бар көчне икенче уракка туплау зарурлыгы алга килеп басты. "Киекле", "Игенче", шулай ук "Рассвет","Кондырча", Мичурин исемендәге хуҗалыклар бу эшне уңышлы гына башлап та җибәрделәр инде. Башка хуҗалыкларга да бу эштә нәрсә дә булса кәтәргә калмады - былтыр шикәр чөгендере казуның, аннан соң ташуның ахырга таба ничек авырга килгәнен һәркем яхшы хәтерли торгандыр.***

***Туңга сөрү тиешленең яртысыннан артыграк мәйданда уздырылды. "Тернәс", Мичурин исемендәге, "Заря", "Сөлчә", "Родина", "Дуслык" һәм "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыкларында беренчел планлаштырылган мәйданнарның 65 - 75 проценты эшкәртелде инде. Ә менә "Чирмешән", Кузнецов исемендәге, "Алга","Комбайн", шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында бу төр план үтәлеше 25 - 40 процент тирәсе генә әле. Соңгы бер көндә район буенча 1400 гектардан артыграк кына җир эшкәртелде. Кайбер хуҗалыкларда сөрү тракторларының көнлек җитештерүчәнлеге 3-6 гектардан артмаганда бу гаҗәп тә түгел.***

***Киләсе ел уңышына нигез салу җәһәтеннән сабан ашлыгы орлыклары салып кую да көн үзәгендә торырга тиешле эшләрнең берсе булып кала килә. Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенә бирелгән мәгълүматларга караганда, "Родина","Кондырча" һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыгында бүгенгә кадәр бер генә тонна борчак, икенчесендә, шулай ук Хафизов исемендәге һәм "Чирмешән" хуҗалыкларында бодай орлыгы салып куелмаган. Соңгысында бу хәлне аңларга да була әле, ә менә бу эшкә гел игътибарлы булган хафизовлылар, кондырчалыларның һәм кайбер башка хуҗалыкларның быелгы пошмаслыгы аңлашылмый.***

***Терлек азыгы хәзерләү эше дә чиратка куела торганнардан түгел. Кичәге көнгә силоска дигән кукурузның яртысы урып алынды инде. Синдряков исемендәге хуҗалыкта силос салу планын яртысыннан күбрәккә үтәделәр, "Заветы Ильича"да, нефтебаза һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында силос планның яртысы чамасы. Дөрес, аларның беренчесендә әле урасы кукуруз да шактый булуы ул планның артыгы белән үтәләсенә ышаныч бирә. Ә менә кайбер хуҗалыкларда быел ул яктан да әллә ни өмет юк. Терлек азыгының, бигрәк тә концентрат азыкның иркен булмасын исәпкә алганда, бүген дуңгызлар өчен катнаш азык салып куюны ашыктырырга кирәклеген көн туса тәкърарлап торулары аңлашыла торгандыр. Мичурин исемендәге хуҗалыкта катнаш азыкны берьярым план күләмендә салдылар инде, "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгында да планның яртысы кадәр бар ул. Кузнецов исемендәге, Синдряков исемендәге хуҗалыкларның дуңгызлары да кышын ач булмас дип уйларга кирәк. Район буенча ун хуҗалыкта бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык бирәмлеге 20 центнердан күбрәк инде. Шул ук вакытта ике хуҗалыкта ул күрсәткеч әле 10 центнерга да тулмаган, бишесендә 10,5 -13 центнер гына.***

## ИГЪТИБАР: ИҖАТ КИЧӘСЕ

***Газета укучыларыбызның исенә төшерәбез: инде хәбәр иткәнебезчә, бүген Нурлат район мәдәният йортында якташыбыз - язучы һәм галим Тәлгат Галиуллинның иҗат кичәсе була, ул 18 сәгатьтә башлана. Кичәдә якташыбызның каләмдәшләре - мәртәбәле язучылар, шагыйрьләр, әдәбият белгечләре дә катнашачак.***

***Барлык әдәбият сөючеләрне иҗат кичәсенә чакырабыз.***

Оештыру комитеты.

*Рәсми хроника*

## ЯҢА ДИРЕКТОР

Узган атнада "Татспиртпром" җитештерү берләшмәсе "Тәрнәс спирт заводы" дәүләт унитар предприятиесе директоры алышынды. Хәзер бу вазифага **Ринат Галимулла улы СУНЕЕВ** сайланды.

## *Киснен сигнал*

# Бензин ягып су ташыйкмы?

"Алга" хуҗалыгыннан сөт комбинатына җибәрелә торган продукциянең еш кына сыйфатсыз булуы турында язгалап торабыз. Шуның аркасында хуҗалыкның сөтен кире боргалаган очраклар да бар. Әле менә шушы арада гына комбинат һәм авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сыйфат буенча дәүләт инспекциясе белгечләре катнашында узган тикшерү монда сөтнең сыйфаты турында һаман да тиешенчә кайгыртмауларын күрсәтте.

Әмма анысы турында сүз аерым әле. Бу юлы авыл халкыннан җыела торган сөтнең тыгызлыгы нормативтан түбән булуы, икенче төрле әйткәндә, аның сыеклыгы, ягъни сөткә су кушылуы да бик гаҗәпкә калдырган. Дөрес, андый кыек эш белән сөт тапшыручыларның барысы да шөгыльләнә диеп әйтәсе килми. Тикшерү көнне җыелган 17 бидон сөтнең икесе генә стандартка туры килми торган булып чыккан. Ике төрле җитешсезлек борчый - сөткә су кушу яки өстен алып тапшыру. Андый "уйлап табучыларның" кемнәр икәнлеге дә билгеле һәм шундый эксперментларын тагын да кабатлый калсалар, икенче юлы исемнәрен дә әйтеп язарга ниятләп торабыз. Ә нигә хуҗалык сөт ташу машинасына бензин әрәм итеп, Нурлатка сөт урынына су ташырга тиеш ди әле?

## ** РЕСПУБЛИКАБЫЗДА*

**** <u>Күптән түгел янә бер китап "табадан төште".</u> Ул - Татар ПЕН - үзәгенең "Мәгариф" нәшрияты белән берлектә әзерләнгән "Бүгенге татар әдәбияты" ("Татарская литература сегодня") җыентыгы, китап инглиз телендә нәшер ителгән.***

***Әлеге хезмәткә аксакалыбыз Гомәр Бәшировтан алып Лиана Әмирханова кебек яшь каләм осталары әсәрләре дә кертелгән. Анда барлыгы 32 авторның иҗат җимеше тупланган.***

**** <u>Татарстан Республикасы Диния нәзарәте тарафыннан "Дин вә мәгыйшәт" газета - бюллетене нәшер ителә башлады.</u> Ничә еллардан соң әлеге кадерле басма татар халкына кире әйләнеп кайтты.***

# ТВ

## ПОНЕДЕЛЬНИК
## 14 СЕНТЯБРЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00 -8.00 "Чулпан"
18.05 Балалар өчен. Г.Х.Андерсен. "Оле Лукойе"
18.35 Музыка ТРТ
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Ислах"
19.45,21.45 Новости
20.00 Рөстәм Утәй җитәкчелегендәге "Татарстан" ДТРК оркестры концерты.
20.25 "Тамчы"
21.00 "Еще раз про любовь"
22.45 "Хоккей для всех"

### ОРТ

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.55 Новости.
9.15 18.20 **"Роксолана - пленница султана".**
9.55 "Поле чудес".
10.50 Здоровье.
11.20 Домашняя библиотека.
11.30 19.30 Угадай мелодию.
12.15 "Вместе".
13.00 Х/ф **"Свой среди чужих, чужой среди своих".**
15.20 "Тин-Тин идет по следу".
15.45 Марафон -15.
16.05 Звездный час.
16.40 **"Новые приключения Синдбада".**
17.10 "...До 16 и старше".
17.30 "Вокруг света".
19.05 Час пик.
20.00 "Мы".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 **"Горец".**
22.50 "Серебряный шар". Марк Прудкин.
23.35 А.С.Пушкин: собрание киносочинений.

### «РОССИЯ»

7.00 Доброе утро ,Россия.
10.00 **"Санта-Барбара"**
10.45 На заметку.
10.50 Мультфильм.
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.30 **"Живет такой парень"**.Х/ф.
13.05 Старая квартира.
14.35 **"Донская повесть"**. Х/ф.
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30 **"Первые поцелуи".**
17.30 Башня.
18.00 Любовь с первого взгляда.
18.30 Автоспорт: национальная гоночная серия.
19.30 **"Грязные танцы"**
20.30 Подробности.
20.45 Сам себе режиссер
21.15 **"Подпольные асы"** (США).Х/ф.
23.00 Акуна Матата.
0.30 Автошоу.

### РИО

17.05 ДИСК-канал. 17.30 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. Сводка за неделю. 17.50 Видеоклипы. 18.00 Те Кто. 18.50 "Дежурная аптека III", 37 серия. 19.30 Ток-шоу "МУЗЫКА И ПРЕССА". 20.30 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.55 "Бриско Каунти. Приключения на Диком Западе". 21.50 Фильм "Деловые люди". 23.30 "ТВ-6" - Красноярск. 23.50 ТСН-6. 0.00 Дорожный патруль. 0.15 ДИСК-канал. 1.00 "Знак качества".

## ВТОРНИК
## 15 СЕНТЯБРЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 "Чулпан"
18.10 Мультфильмы
18.35 Музыка ТРТ
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 Кол Гали. "Кыйссаи Йосыф"
19.45,21.45 Новости
20.00 "Замандаш"
20.30 "Әлли - бәлли -бәү"
21.00 "Млечный путь"
22.50 "Бизнес ТВ "

### ОРТ

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 1.05 Новости.
9.15 18.20 **"Роксолана - пленница султана".**
10.00 "Мы".
10.45 Смехопанорама
11.20 Домашняя библиотека.
11.30 Угадай мелодию.
12.15 "Вместе".
13.00 **"Вход в лабиринт"Х/ф.**
14.20 Футбольное обозрение.
15.20 "Тин-Тин идет по следу".
15.55 Счастливый случай.
16.40 **"Новые приключения Синдбада".**
17.10 "...До 16 и старше".
17.30 "Вокруг света".
19.00 Футбол.
19.50 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 **"Два билета на дневной сеанс"**. Х/ф.
23.40 "Песня года".
0.20 Хоккей.

### «РОССИЯ»

7.00 Доброе утро ,Россия.
10.00 **"Санта-Барбара"**
10.45 16.00 Мультфильмы
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.30 **"Когда играли Баха","Крейзи".** Х/ф.
14.35 **"Мементо мори"** .
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30 **"Первые поцелуи"**
17.30 Башня.
18.00 Кроссворд.
18.30 **"Матери,жены и любовницы". Х/ф.**
19.30 **"Грязные танцы"**.
20.30 Подробности.
20.45 "Аншлаг"представляет.
21.15 **"Ставки сделаны"**
23.05 **"Пси фактор"**
0.30 Творческий вечер Олега Иванова.

### РИО

7.05 ДИСК-канал. 17.30 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. 17.50 "Любишь-смотри". Видеоклипы. 18.00 Те Кто. 18.50 Юмористический сериал "Дежурная аптека III", 38 серия. 19.30 Ток-шоу Артура КРУПЕНИНА "МУЖСКОЙ КЛУБ". "Стриптиз по-мужски". 20.30 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.55 Сериал "Бриско Каунти. Приключения на Диком Западе", 25 серия. 21.55 КИНОТЕАТР ТВ- 6. Фантастический боевик "Трещина" (Испания). 23.30 "ТВ-6" - Красноярск. 23.50 ТСН-6. 0.00 Дорожный патруль. 0.15 ДИСК-канал. 1.00 "Знак качества". 1.15 Ночной сеанс. "Доля секунды".

## СРЕДА
## 16 СЕНТЯБРЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 "Чулпан"
18.10 Мультфильмы
18.35 Музыка ТРТ
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Сельские будни"
19.25 "Пульс"
19.45,21.45 Новости
20.00 "Карт - бланш"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Земля Санникова"
22.45 "Точка опоры"

### ОРТ

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.45 Новости.
9.15 18.20 **"Роксолана - пленница султана"**.
10.00 Хоккей.
10.40 В мире животных.
11.20 Домашняя библиотека.
11.25 Джентльмен-шоу.
12.15 "Вместе".
13.00 **"Вход в лабиринт"**. Х/ф.
14.15 "Серебряный шар"
15.20 "Тин-Тин идет по следу".
15.45 "Классная компания".
16.15 Зов джунглей.
16.40 **"Новые приключения Синдбада".**
17.10 "...До 16 и старше".
17.30 "Вокруг света".
19.05 Час пик.
19.30 "Золотая лихорадка".
20.10 Человек и закон.
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 "Ловец солнца"
0.00 Док.детектив. "Убийство в монастыре".
1.00 Х/ф **"Багз-2".**

### «РОССИЯ»

7.00 Доброе утро ,Россия.
10.00 **"Санта-Барбара"**
10.45 "Стронг"представляет.
10.50 На заметку.
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.30 **"Цыган"** . Х/ф .
12.50 Старая квартира
14.35 **"Фуфель"** . Х/ф.
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30 **"Первые поцелуи"**
17.30 Башня.
18.00 Вояж-турнир .
18.30 **"Матери,жены и любовницы"Х/ф.**
19.30 **"Грязные танцы"**
20.30 Подробности.
20.45 "Два рояля".
21.30 "Устрицы из Лозанны" Х/ф.
23.00 "Агата Кристи. Пуаро".
0. 30 Горячая десятка.

### РИО

17.05 ДИСК-канал. 17.30 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. 17.50 "Любишь-смотри". Видеоклипы. 18.00 Те Кто. 18.55 Юмористический сериал "Дежурная аптека III", 39 серия. 19.30 Ток-шоу "Я САМА" . "А я юношей люблю...". 20.30 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.55 "ТВ-6 " - Красноярск. ЭТО НАШЕ ШОУ ! 23.20 "ТВ-6" - Красноярск. 23.45 ТСН-6. 23.55 Дорожный патруль. 0.10 ДИСК-канал. 0.55 "Знак качества". 1.10 Ночной сеанс. "Малкольм".

## ЧЕТВЕРГ
## 17 СЕНТЯБРЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 "Чулпан"
18.10 Мультфильмы
18.35 Музыка ТРТ
18.45, 20.45 "Җиһан"
19.00 Играет духовой оркестр...
19.25 "Эхо голоса твоего"
19.45,21.45 Новости
20.00 "ГАИ - информ"
20.15 "Агым"
20.30"Әлли-бәлли - бәү"
21.00 "Приключение - это приключение"

### ОРТ

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.00 Новости.
9.15 18.20**"Роксолана-пленница султана"**
10.00 Человек и закон.
10.35 Пока все дома.
11.20 Домашняя библиотека.
11.25 19.30 "Эти забавные животные"
12.15 "Вместе".
13.00 **"Вход в лабиринт"**. Х/ф.
14.10 Умники и умницы
15.20 "Невероятные приключения Джонни Квеста".
15.45"Классная компания".
16.10 Детские анекдоты.
16.40**"Новые приключения Синдбада".**
17.10 ...До 16 и старше.
17.30 Вокруг света.
19.05 Час пик.
20.05 "В поисках утраченного".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 **"Одинокая женщина желает познакомиться".**
23.30 "Тринадцать чемпионов" . Х/ф
0.20 "Багз-2". Х/ф.

### «РОССИЯ»

7.00 Доброе утро ,Россия.
10.00 **"Санта-Барбара"**
10.45 Мир здоровья.
10.50 На заметку.
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.30 **"Какие наши годы".** Х/ф.
12.50 Старая квартира
14.35**"Тайна виллы"**.
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30 **"Первые поцелуи".**
17.30 Башня.
18.00 Слабо?
18.30 **"Матери, жены и любовницы".**
19.30 **"Грязные танцы"**
20.30 Подробности.
20.45 "Добрый вечер!"
21.15**"Коротышка из Майями".** Х/ф
23.05 **"Притворщик"**
0.30 Адамово яблоко.

### РИО

17.05 ДИСК-канал. 17.30 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. 17.50 "Любишь-смотри". Видеоклипы. 18.00 Те Кто. 18.50 Юмористический сериал "Дежурная аптека III", 40 серия. 19.30 Ток-шоу "СДЕЛАЙ ШАГ". 20.30 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.55 "Бриско Каунти. Приключения на Диком Западе", 26 серия. 21.50 Л.Дуров, Е.Майорова в фильме "Тридцать четвертый скорый". 23.25 "ТВ-6" Красноярск. 23.50 ТСН-6. 0.00 Дорожный патруль. 0.10 ДИСК-канал. 0.55 "Знак качества". 1.10 Боевик "Дикарь"

## ПЯТНИЦА
## 18 СЕНТЯБРЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 "Чулпан"
17.55 "Йолдызлар һәм йолдызчыклар"
18.35 Музыка ТРТ
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Батулла дәресләре"
19.20 "Дин һәм тормыш"
19.45,21.45 Новости
20.00 "Музыкаль сәхифә"
20.30"Әлли - бәлли -бәү"
21.00 "Җомга көн кич белән"
22.00 Хәмдүнә Тимергалиева концерты

### ОРТ

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.20 Новости.
9.15 18.20**"Роксолана - пленница султана"**.
10.05 Клуб путешественников.
10.55 Смак.
11.15 Домашняя библиотека.
11.25 "Играй, гармонь любимая!".
12.15 "Вместе".
13.00 **"Я,следователь..."**
15.20 **"Что-то страшное грядет"**. Х/ф.
16.55 "Улица Сезам".
17.25 "Чердачок Фруттис".
19.10 Здоровье.
19.45 "Поле чудес".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 **"Убийство в трех актах"**.Х/ф.
23.35 Взгляд.
0.35 **"Кодовое имя - солдат"**. Х/ф.

### «РОССИЯ»

7.00 Доброе утро ,Россия.
10.00 **"Санта-Барбара"**
10.45 Мир здоровья.
10.50 На заметку.
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.30**"Пропал друг".Х/ф**
12.35 Старая квартира
13.45 Торговый дом "Ле Монти".
14.35**"Неоконченная повесть"**. Х/ф.
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30**"Первые поцелуи"**
17.30 Башня.
18.00 У всех на устах.
18.30 **"Матери, жены и любовницы"**.
19.30 "Марьина роща".
20.30 Подробности.
20.45 "Городок".
21.20 Маски-шоу.
22.20 Музыкальный ринг.
0.30 **"Елена в ящице"**.

### РИО

17.05 ДИСК-канал.
17.30 ТСН-6.
17.35 Дорожный патруль.
17.50 Видеоклипы.
18.00 Те Кто.
18.50 "Дежурная аптека III", 41 серия.
19.30 КАТАСТРОФЫ НЕДЕЛИ.
20.00 "ВЫ - ОЧЕВИДЕЦ".
20.30 "НОВОСТИ ДНЯ".
20.55 "Ради женщины" (Испания).
23.00 "ОБОЗ - шоу".
23.55 "ТВ-6" - Красноярск.
0.15 "Такси ТВ-6".
0.30 ТСН-6.
0.40 Дорожный патруль.
0.55 ДИСК-канал.
1.40 "Знак качества".

## СУББОТА
## 19 СЕНТЯБРЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 "Чулпан"
17.35 "Хәерле сәгатьтә" Буа районы
18.35 Музыка ТРТ
18.45 "Җиһан"
19.00 "Бизнес ТВ"
19.45 Новости
20.00 "Чай или кофе"
20.30 "Әлли- бәлли -бәү"
20.50 "Көрәшчеләр өчен көрәшүче"
21.35"Видеоспорт-авто"
22.05 "Җырлы гомер"
22.30 "Точка опоры"

### ОРТ

8.00 **"Голова Горгоны"**. Х/ф.
9.45 Слово пастыря.
10.00 15.00 18.00 Новости.
10.10 Домашняя библиотека.
10.30 "Утренняя почта".
11.10 "Каламбур".
11.45 Смак.
12.05 "Возвращение Третьяковки".
12.25 Леонид Коган. "Мгновения жизни и славы..."
13.15 "Им покоряется небо".
15.20 "Цивилизация".
15.50 В мире животных
16.30 Мультфильм.
17.15 Как это было.
18.25 Джентльмен- шоу
19.05 **"Мистер Питкин в тылу врага".**
20.45 "Спокойной ночи, малыши!".
21.00 Время.
21.40 **"Достучаться до небес"** .Х/ф.
23.25 "Задоринки"М. Задорнова.
0.25 **"Забыть Рангун"**

### «РОССИЯ»

8.00 Утро крестьянина.
8.30 Служу Отечеству!
9.00,9.30 Мультфильм.
10.00 Доброе утро, страна!
10.35 "Любовь с первого взгляда".
11.05 "Вальс-бостон".
12.00 Подиум д'арт.
12.30 Домашние хлопоты Н.Варлей.
13.00 **"Неделя в Санта - Барбаре"**
14.00 20.00 Вести.
14.30**"Странные люди"**
16.10 "Закон и порядок"
17.00 **"Урга - территория любви"**.
19.00 Моя семья.
20.30 Добрый вечер с Угольниковым .
21.15 **"Пленники небес"** .Х/ф.
23.30 Праздник "МК"в Лужниках.
0.25 Х/ф **"Экзотика"**.

### РИО

7.05 Дорожный патруль. 7.20 ДИСК-канал. 8.05 14.25 М/ф. 8.25 "ТВ-6" - Красноярск. 8.45 "Туфли с золотыми пряжками"9.55 "Спасибо за покупку!". 10.05 "Робин Гуд". 11.05 "З.К.". 11.30 ТСН-6. 11.45 "Не горюй". 13.25 "Спасибо за покупку!". 13.50 Территория ТВ-6. 15.10 Кинескоп. 16.15 "Такси ТВ-6". 16.30 Видеоклипы. 16.40 ДИСК-канал. 17.30 0.35 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. 17.50 Путешествия с "Национальным Географическим Обществом"18.50 "Звезды о звездах". 19.25 Видеоклипы. 19.40 "О.С.П. - Студия". 20.30 Скандалы недели. 21.00- "Фитиль". 21.20 "Криминальное время". 23.40 "ТВ-6" - Красноярск. 0.00 "Шоу Бенни Хилла"0.45 "З.К.". 1.05 "Такси ТВ-6". 1.20 "Святые грешники"

## ВОСКРЕСЕНЬЕ
## 20 СЕНТЯБРЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.45 "У зеленого камина". Туфан Миңнулин.
18.20 "Видеоспорт"
18.35 Музыка ТРТ
18.45 "Телебуклет"
19.00 "ТОН"
19.40 Автокалейдоскоп
20.00 "Ханым"
20.30"Әлли - бәлли - бәү"
20.45 "Шаян - шоу"
21.15 Ф.Бүләков. "Әбиләргә ни җитми?"

### ОРТ

8.00 **"Приказано взять живым".**
9.30 16.40 "Дисней-клуб".
10.00 15.00 0.40 Новости
10.10 "Непутевые заметки".
10.30 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 Армейский магазин.
12.30 "Играй, гармонь любимая!".
13.00 Крестьянские ведомости.
13.30 "Подводная одиссея команды Кусто".
14.20 Смехопанорама.
15.20 Клуб путешественников.
16.05 Футбольное обозрение.
17.35 "Колесо истории".
18.25 КВН-ассорти .
18.55 "Ералаш".
19.05 **"Осенний марафон" Х/ф.**
20.55 Киноафиша.
21.00 Время.
21.35 **"Крепкий орешек"**.
0.10 "Абажур".
0.55**"Простофиля артачится"**.Х/ф.

### «РОССИЯ»

8.00 Мультфильм.
8.20 **"Арабела-дочь пирата"**.Х/ф.
9.30 Почта РТР.
10.00 Доброе утро, страна!
10.30 Сам себе режиссер.
11.00 "Аншлаг" представляет.
11.30 "Городок".
12.00 Русское лото.
12.45 "Мир книг с Л.Куравлевым".
13.00 "Неделя в Санта-Барбаре".
14.00 Вести.
14.30 Федерация.
15.15 Парламентский час.
16.10 **"Закон и порядок"**.
17.00 Диалоги о животных.
18.00 Футбол.
20.00 Зеркало.
20.55 **"Ты у меня одна"**.
22.40 **"Страшная история". Х/ф.**
0.15 "К-2" представляет: "Колизей".

### РИО

7.05 Дорожный патруль. 7.20 ДИСК-канал. 8.05 13.45 М/ф. 8.20 "ТВ-6" - Красноярск. 8.40 "Туфли с золотыми пряжками". 9.50 "Робин Гуд". 10.55 Шоу еды . 11.30 ТСН-6. 11.45 "Ювелирная лавка". 13.30 "Спасибо за покупку!". 14.05 "КАНОН". 14.35 Ток-шоу "Я САМА" . 15.35 Док. сериал 16.10 "Такси ТВ-6". 16.25 Спорт недели. 17.00 "Назло рекордам!". 17.30 ТСН-6. 17.40 Дорожный патруль. Сводка за неделю. 17.50 Путешествия с "Национальным Географическим Обществом"19.00 "Обозреватель". 20.05 "ТВ-6" - Красноярск. 23.10 "Страсти по Анжелике".0.25 "Шоу Бенни Хилла". 0.55 "Такси ТВ-6". 1.15 "Убийство №1".



# ГӨМБӘДӘН САК БУЛЫГЫЗ!

***Соңгы вакытта республикада гөмбә ашап каты агулану очраклары кискен артты. Июнь ахырыннан август башына кадәр генә дә шундый 20 очрак теркәлде. Зыян күргән 37 кешенең бишесе үлде.***

Тикшерү күрсәткәнчә, ул кешеләр гөмбәнең ашарга яраклысын агулысыннан аермаучылар булып чыккан. Җыйган гөмбәне дә эшкәртү кагыйдәләрен белмәүчеләр күп. Еш кына гөмбәне юмыйлар, суда тотмыйлар һәм пешермиләр.

Гөмбә белән агуланудан ничек котылырга соң? Иң элек гөмбәнең ашарга яраклы, шартлы рәвештә генә яраклы һәм агулыларын аера белергә кирәк. Ашарга яраклы гөмбәләрнең 100гә якын төре бар һәм тиешенчә эшкәрткәннән соң аларны курыкмыйча ашарга мөмкин. Кәҗә гөмбәсе (сморчок), ал гөмбә (свинушка) һәм кайбер башка гөмбәләр шартлы рәвештә ашарга яраклылар рәтенә керәләр, чөнки аларда күпмедер дәрәҗәдә агулы матдәләр була, әмма эшкәртү кагыйдәләрен төгәл үтәп әзерләгән очракта аларны курыкмыйча ашарга мөмкин. Шуны исегездә тотыгыз, агулы гөмбәләр барысы да пластинкалы булалар, ягъни аларның эшләпә асларында гөмбә аягыннан эшләпә читенә кадәр җилпәзә рәвешендә пластинкалар тезелеп киткән була. Димәк, пластинкалы гөмбәләрнең берсен дә җыярга ярамый.

Бары тик трубкасыман: ак, усак, каен гөмбәләрен, майлы гөмбәне, моховикны һәм башка гөмбәләрне генә җыярга кирәк. Ул гөмбәләрне танырга бик җиңел: аларның эшләпәләренең аскы ягы шома яки күзәнәкле була.

Агулы гөмбәләр ничек кенә эшкәрткәндә дә сәламәтлек өчен зарарлы. Бу бигрәк тә поганкага, чебен гөмбәсенә кагыла, аксыл поганка белән бигрәк тә каты агуланырга мөмкин. Аларның соңгысындагы агулы матдә - алколоидлар термик эшкәрткәндә дә чыгып бетми, организм тарафыннан тиз үзләштерелә. Алар бигрәк тә бавыр, бөерләргә һәм үзәк нерв системасына зур зыян китерәләр.

Андый агулы матдәләрнең яшерен тәэсире гөмбә ашаганнан соң 8 сәгатьтән бер тәүлеккә кадәр бара. Гөмбә белән агулануның беренче билгеләре - күңел болгану, еш косу, эч авырту, тәрәт нык сыеклану, торган саен хәлсезләнү. Андый очракта кичекмәстән табиб чакыртырга яки авыру кешене сырхауханәгә илтергә кирәк.

Чебен гөмбәсенең агулы тәэсире 5 - 6 сәгатьтән соң беленә; алда санап үтелгән билгеләрдән тыш, бу очракта кеше бик каты тирли, селәгәе агу арта, өске сулыш юлларыннан күбек килә, тыны бетә, кеше зәңгәрләнә, күз алмалары кечерәя.

Шартлы рәвештә ашарга яраклы гөмбәдән дә агуланырга мөмкин, әмма ул агулануны кеше җиңелрәк кичерә һәм ул бер - ике тәүлектән соң уза.

Дөрес эшкәртелмәгән гөмбә ботулизм кебек каты авыруга да китерергә мөмкин. Гөмбә тозлаганда яки маринадлаганда аларны яхшылап юарга һәм чистартырга, аннан, гөмбәгә ябышкан балчык һәм аның белән бергә ботулинус споралары да эләкмәсен өчен тагын берничә кат юарга кирәк. Чөнки алар герметик итеп ябылган банкада да үрчиләр һәм килеп чыккан микроблар үтергеч дәрәҗәдә агулы матдә эшләп чыгара башлыйлар.

Гөмбәне яшь балаларга, бик олы кешеләргә, ашказаны трακты, бавыр һәм бөере авырткан кешеләргә ашатырга киңәш ителмәвен истән чыгармаска кирәк.

Кеше гөмбә ашап агуланган очракта, табиб килеп җиткәнче ниләр эшләргә кирәклеген дә белеп тору мөһим. Иң элек аның ашказанын һәм эчәклеген чистартырга кирәк. Ашказанын чистарту өчен күп итеп җылы су, сода яки сыек кына марганцовка эретмәсе эчертәләр, мәҗбүри костыралар. Эчәклекне чистарту өчен кастор мае, тоз, клизма файдалы. Ә инде организмда кимегән сыеклык һәм тозларны тулыландыру өчен авыруга әз - әзләп кенә тозлы су һәм каты чәй йоттырырга кирәк. Исерткечле эчемлекләр куллану һич тә рөхсәт ителми - алар, киресенчә, агулы матдәләрнең организмга үтеп керүен тизләтә генә.

Дәвалау учреждениеләрендә гөмбә белән агуланучыларны дәвалау өчен кирәкле бөтен чаралар да бар. Әмма нинди генә чара да гөмбә белән агуланучыны бирегә агулану котылгысыз нәтиҗәләргә китергәнче илтеп җиткергәндә генә файда бирә. Моны һәр кеше истә тотарга тиеш.

**Л.НӘБИУЛЛИНА,**
**санэпидкүзәтү үзәгенең санитар агарту буенча инструкторы.**

***Гөмбә җыю, эшкәртү һәм сатуның санитар кагыйдәләреннән:***

***Базарларда:***

***- пешерелгән, тозланган, маринадланган гөмбә белән,***

***- гөмбә икрасы, гөмбәле тозланмалар, салатлар һәм вакланган гөмбәдән ясалган башка азык -төлек,***

***- өй шартларында "консервлап" капкачланган банкалардагы гөмбәләр белән сату итү катгый тыела.***



## Көзге салат

Ун 1 литрлы банкаларга 1,6 кг яшел борыч, 4,4 кг кәбестә, 1,6 кг кишер, 1,2 кг башлы суган. Яшелчәләрне яхшылап чистартып юарга, ваклап турарга яки кыргыч аша кырырга. Зур кәстрүлгә салып, 150 г тоз, 50 г шикәр комы, 0,9 литр 6 процентлы аш серкәсе, 90 г үсемлек мае өстәргә. Бөтенесен яхшылап болгатырга һәм банкаларга тутырырга.

Банкаларга тутырган чакта һәрберсенә түгәрәк кара борыч, 2 - 3 лавр яфрагы салырга. Тутырылган банкаларны стерильләштерергә (0,5 литрлы - 20 минут, 1 литрлы - 30 минут), махсус капкачлар белән каплап куярга.

***Шундый ук ысул белән әзерләнә торган тагын 2 салат тәкъдим итәбез.***

## Украин салаты

Томат (яшел яки алсу) - 4 кг, кызыл борыч - 2 кг, кишер - 1 кг, башлы суган - 1 кг, петрушка (тамыры) - 400 г, тоз - 200 г.

Май, шикәр комы, аш серкәсе һәм тәмләткечләрне көзге салаттагы кебек салырга.

## Дунай салаты

Томат (яшел яки алсу) - 3,5 кг, кызыл борыч - 2,4 кг, кишер - 1,8 кг, яшел борчак (консервланган) - 1,2 кг, тоз - 300 г, үсемлек мае - 800 г, аш серкәсе (6 процентлы) - 0,8 литр.

Тәмләткечләр һәм шикәр комы көзге салаттагы кебек салына.

## Эремчек белән помидор салаты

2 аш кашыгы эремчек, 1 аш кашыгы сөт, 1 балкашык үсемлек мае, кечкенә кисәкләргә бүленгән 1 помидор алына. Шуларга тоз өстәп болгатыгыз. Эремчек белән кыяр салаты. 2 аш кашыгы эремчек, 1 аш кашыгы сөт, 1 балкашык үсемлек мае, вакланган 1 кыяр, бераз петрушка үләне. Тоз өстәп болгатыгыз.

Эремчеккә сөт кушасың да үсемлек мае өстисең һәм нинди дә булса бер яшелчә кирәк була.

Болгар борычы, редиска, торма, кишер, суган, укроп, петрушка - барын да кулланырга мөмкин.

## Салат

3 кг помидор, 1 кг башлы суган, 1 кг татлы борыч, 1 кг кәбестә турап, 1 кг кишерне угычта уып, 4 аш кашыгы тоз, 3 аш кашыгы шикәр комы, 300 г көнбагыш мае өстәп, болгатып пешерергә куегыз.

Кайнап чыкканнан соң тагын 30 минут пешерегез. Әзер салатны стерильләштерелгән пыяла савытларга тутырып ябарга кирәк.

## Крыжовник кагы

Пешкән һәм яхшылап юылган крыжовникны савытка бушатып, өстенә су салырга (1 кг җиләккә - ким дигәндә 2 стакан су). Акрын утта пешерергә куегыз һәм пешә барган уңайга җиләкләрне агач көрәкчек белән кәстрүл (яки башка савыт) уртасына күбек җыела башлаганчы пешерегез. Азрак суынгач, шул массаны орлык - төшләреннән сөзеп алырга кирәк. Аннары сөзелгән массага шикәр комы өстәп (1 кг массага 500 г исәбеннән), тагын утка куегыз. Болгата - болгата, куерганчы кайнатыгыз. Менә әзер дә булды. Хәзер инде шул как массасын печенье пешерә торган формаларга салып, өстенә шикәр оны, уылган конфет вагы сибегез дә - салкын урынга куегыз.

Какны өсте майланган такта өстенә җәеп киптерү юлы белән дә ясыйлар.

## КОТЛЫЙБЫЗ!



11 сентябрьдә минем яраткан **тормыш иптәшем Галия Хәсәнгатинага** 50 яшь тула. Исәнлек - саулык, озын гомер, бәхетле тормыш теләп **тормыш иптәше Фоат, улы Ирек.**

Кәкре Атау авылында яшәүче кадерле **тормыш иптәшем, әтиебез, бабабыз Иксан Хасыйбулла улы Гыйззәтуллинга** 17 сентябрьдә 60 яшь тула. Без аны олы юбилее белән котлыйбыз.



Якын итеп кайтып йөрсен
Балалар - оныкларың.
Тигезлек, татулык булса -
Сиңа ни кирәк тагын!
Сәламәт бул, кайгы күрмә,
Йөзең гел ачык булсын,
"60 яшь ул - егет чак",- дип
Яшәргә насыйп булсын!
**Тормыш иптәшең, кызларың - кияүләрең, улларың-киленнәрең, оныкларың.**


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Газ исәплүгечләр. Үзебезнең илдә эшләнгән, 6 куб.метрга исәпләнгән, хакы 450 сум.**
Тел.: 5-33-28, кичке 7дән соң.
***
**"Шикәрче - 1" ширкәтендә 5 сутыйлы дача, йорты, җиләк - җимеш үсентеләре бар.** Адрес: Гоголь ур., 15
***
**1995 елгы, бик әйбәт хәлдәге "УАЗ - буханка", вагон, 10 х 1,5 метрлы рабица челтәре.** Тел.: 5-35-91
***
**Әйбәт хәлдәге ЗАЗ - 968.** Адрес: Дружба ур., 78 - 18
***
**Мир урамында капиталь гараж.** Тел.: 5 -13-60.
***
**СПТУ микрорайонында төзелеш өчен участок.** Тел.: 5-24-01.
***
**Чия төсендәге ВАЗ-21053, бәясе - килешү буенча.** Тел.: 5-27-68.
***
**1998 елның мартында чыккан ВАЗ-2107.** Тел.: 5-20-41 (өй), 5-13-87 (эш).
***
**Чишмә поселогында йорт.** Адрес: К.Маркс ур., 6-42, тел.: 5-33-62, кичке 8дән соң.

### ФАТИР КИРӘК

**Илья чиркәве рухание шәһәр үзәгендә яки чиркәүгә якынрак урында бер яки ике бүлмәле фатир эзли.** Гагарин ур., 12 - 15 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

### ЭШКӘ ЧАКЫРАБЫЗ

***Октябрь МСОсының 1нче ПМКсына сыек һәм газ ягулыгында эшли торган казан җайланмаларына таныклыгы һәм эш стажы булган операторлар.***
Администрация
***
**Аэропорт ресторанына савыт - саба юучы һәм официанткалар кирәк.**
Аэропортка яки "Иверия" кибетенә мөрәҗәгать итәргә.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

***Дәүләт салым инспекциясендә "кайнар" телефоннар эшли.***

Халык предприятиеләрдә салым тәртибен бозулар турында 2-28-03, физик затларның салым тәртибен бозулары турында 2-10-59 номерлары белән шалтыратып хәбәр итә ала.
***
**Станислав Аркадьевич Петров исеменә документлар табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйбыз.** Адрес: Урта Камышлы авылы.

### ЭКСПРЕСС - ҮЗӘК

**Чит илдә чыккан теле - видео аппаратуралар ремонтлау буенча яңа хезмәт тәкъдим итә.**
***
**Сатуда һәрчак төрледән - төрле компьютерлар һәм аксессуарлар, оргтехника, фототоварлар, электр җиһазлары.**
***
**Компьютерлар һәм оргтехниканы ремонтлау һәм заманчалаштыру хезмәтләре күрсәтә.**
***
**А 4 форматта ксерокүчермәләр ясый.**
***
**Һәркөнне иртәнге 8дән кичке 6га кадәр эшли (төшке аш вакыты көндезге 1дән 2гә).**
Адрес: Нурлат шәһәре, Мәктәп ур., "Көнкүреш йорты", 2нче кат, тел.: 5-37-51.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**
**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясендә офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. № 3552